ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 июля 2015 г. № 4296

Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясының 1 пункты, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага «Интернет» челтәрендә тиешле мәгълүмат системаларында һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен, муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын «Мәгълүмати технологияләр үзәге» МАУга бирүне тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җирләрдән формалаштырылган җир участогын торак төзелеше өчен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 13 августындагы 4794 номерлы карары, «Торак пунктлар

җирләреннән җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 4 мартындагы 1267 номерлы карары, «Торак пунктлар җирләреннән җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 4 мартындагы 1268 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Н.Г. Мәһдиев

Башкарма комитетның
2015 елның 29 июлендәге
4296 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга
милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба - муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламент дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – ҖММИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан урамы, 23 йорт.

ҖММИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан урамы, 23 йорт, 233 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре;

төшке аш вакыты: 12.00 дән13.00 гә кадәр.

ҖММИнең  белешмә телефоны: 30-55-54.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының рәсми сайты адресы: (http:/ www.nabchelny.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет (ҖММИ) бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http:/ www.nabchelny.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http:/www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (ҖММИ):

1) телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон буенча;

2) язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта (uzioip@yandex.ru) аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат ҖММИ белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен ҖММИ бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Граждан кодексының 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (РФ законнары җыентыгы, 05.12.1994, №32, ст. 3301 ) (алга таба – РФ Граждан кодексы);

2) Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 №136-ФЗ (РФ законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, ст. 4147 ) (алга таба – РФ Җир кодексы);

3) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822 ) (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон);

5) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

6) Татарстан Республикасы Җир кодексы 10.07.1998 № 1736 (алга таба – ТР Җир кодексы) (Татарстан Республикасы, №10-11, 22.01.2005);

7) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы;

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы);

9) Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары (алга таба – Муниципаль хезмәтләр исемлеге);

10) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 декабрендәге 1259 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти

мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – ҖММИ турында нигезләмә);

11) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

1) техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 2 пункты). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир участогын индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү | РФ Җир кодексының 39.18 статьясы<br>Муниципаль хезмәтләр исемлеге |
| 2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән ҖММИ | 210-ФЗ номерлы ФЗ<br>РФ Җир кодексының 39.18 статьясы<br>Шәһәр Уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Җир участогын сату-алу (арендалау) шартнамәсе.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Җир кодексының 39.16 статьясы,<br>39.18 статьясы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гаризаны теркәгән вакыттан башлап 30 көннән артык түгел, хәбәр басылып чыкан вакыттан башлап, сорала торган җир участогын бирү турында башка гражданнарның гаризаларын кабул итү өчен каралган срокны (30 көн) һәм аукцион уздыру турында игълан ителгән вакыттан башлап, аны үткәрү вакытына кадәр срокны (хәбәр басылып чыккан башлап 30 көн эчендә башка затларның гаризалары кергән очракта) (30 көн) кертмичә | РФ Җир кодексының 39.18 статьясының 1, 5, 7пунктлары |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле | 1) Гариза;<br>2) Шәхесне раслаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә); | Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Гариза бирүченең җир участогын |

| | | |
|---|---|---|
| документларның тулы исемлеге | 4) Территорияләрнең кадастр планында җир участогын урнаштыруның расланган схемасы (әгәр җир участогын барлыкка китерергә туры килсә һәм чикләрендә җир участогы барлыкка китерү каралган территорияне межалау проекты расланмаган булса) | сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы; |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектларына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүматлар булган) (бинага, төзелешкә, корылмага хокуклар турында);<br>2) сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе;<br>3) Башкарма комитетның җир участогына адрес бирү турында боерыгы | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү (муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) өчен килештерү таләп ителә | 1) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе<br>2) Башкарма комитетның Хокук идарәсе;<br>3) Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары;<br>3) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе. | Эш регламенты |

| | | |
|---|---|---|
| торган җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге. | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1) Документлар тиеш булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) Тапшырылган документлар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) Документлар тиешле булмаган органга тапшырылу. | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>РФ Җир кодексының 39.18 статьясының 1 пунктының 2 пунктчасында каралган, ягъни түбәндәге очракларда:<br>1) җир участогы бирүне алдан килештерү турында гаризага теркәлгән җир участогының урнашу схемасы Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясындагы 16 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча расланырга мөмкин түгел<br>1) җир участогының урнашу схемасы аның формасына, форматына яки аны әзерләү таләпләренә туры килмәү;<br>2) аның урнашу схемасында барлыкка китерү каралган җир участогының урнашу урыны тулысынча яки өлешчә элек кабул ителгән һәм гамәлдә булу срогы узмаган җир участогының урнашу схемасын раслау турында карар нигезендә барлыкка килә торган җир участогының урнашу урыны белән туры килүе;<br>3) барлыкка килә торган җир участокларына карата таләпләрне бозып, җир участогын урнаштыру схемасын эшләү;<br>4) җир участогының урнашу схемасы территорияне планлаштыруның расланган проекты, җир төзелеше документлары, | РФ Җир кодексының 39.16 статьясы, 39.18 статьясының 1 пунктындагы 2 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | махсус саклана торган табигать территориясе турындагы нигезләмәгә туры килмәү;<br>5) җир участогын урнаштыру схемасында барлыкка китерү каралган җир участогының территорияне межалау проекты расланган территория чикләрендә урнашуы;<br>РФ Җир кодексының 39.16 статьясында каралган, ягъни түбәндәге очракларда:<br>1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә җир участогын сатулар үткәрмичә алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мираска ия булу яки аренда хокукында бирелгән, җир участогы бирү турында гариза белән әлеге хокукларга ия булучы мөрәҗәгать иткән яисә җир участогы бирү турында гариза Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш ( авыл хуҗалыгында, ау хуҗалыгында, урман хуҗалыгында һәм биналар, корылмалар төзүне күздә тотмаган башкача файдалану өчен, андый җир участоклары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм әлеге ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелгән булса, биш елдан артмаган срокка);<br>3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки индивидуаль торак төзелеше максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен, гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага (гариза белән әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш) яисә, әлеге коммерцияле булмаган оешмага бирелгән (әгәр җир участогы гомуми файдаланудагы мөлкәткә керсә); | |

| | | |
|---|---|---|
| | 4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, тәмамланмаган төзелеш объекты урнашу, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) җир участогында сервитут шартларында урнаштырылган яки РФ Җир кодексының 39.36 статьясының 3 пунктының 1 пунктчасында каралган объект (җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында урнаштыру гамәлгә ашырылырга мөмкин булган объектлар. Күрсәтелгән объектларны урнаштыру тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнә) урнаштырылган һәм әлеге җир участогын рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдалануга комачауламый торган яисә җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылманың, алардагы бүлмәләрнең, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектәге бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашу, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) җир участогында сервитут шартларында урнаштырылган яки моңа корылма (шул исәптән төзелеш тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында урнашкан яки җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылманың, алардагы бүлмәләрнең, әлеге төзелеше тәмамланмаган объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән булып тора һәм аны бирү җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокук буенча рөхсәт ителми;<br>7) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган җир булып тора, әгәр гариза бирүче җир участогын милеккә, даими | |

| | | |
|---|---|---|
| | (сроксыз) файдалануга яисә җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән, җир участогын резервлау максатларында җир участогы бирү турындагы карарның гамәлдә булу срогыннан артык вакытка түләүсез файдалануга бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир участогын резервлау максатларында бирелгән очраклардан тыш;<br>8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән төзелә торган территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, җир участогы бирү турында гариза белән шул җир участогында урнашкан бина, корылмалар, алардагы бүлмәләрнең, төзелеше тәмамланмаган объектының милекчесе яки җир участогының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогы чикләрендә урнашкан яки җир участогы башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән ясалган, мондый җир участогы федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир участогын бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аңа карата территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән җир участогыннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документ нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән, җир участогын арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның әлеге объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тотучы территорияне | |

| | | |
|---|---|---|
| | комплекслы үзләштерү турында шартнамә яки төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>11) җир участогын бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы, аны үткәрү турында белдерү РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырылган (аукцион үткәрү турында хәбәр, аукцион үткәрү көненә кадәр кимендә утыз көн алдан, вакытлы матбугат басмасында («Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газетасында) һәм «Интернет» челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (http:/ www.nabchelny.ru) урнаштырыла) аукцион предметы булып тора;<br>12) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата, мондый җир участогы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 4 пунктчасы (территорияне межалауның расланган проекты яки җир участогын урнаштыруның расланган схемасы нигезендә, җир участогын барлыкка китерү максатларында кызыксынган зат тарафыннан кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итү) нигезендә ясалган һәм вәкаләтле орган тарафыннан, РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча, әлеге аукционны үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән булса, аны сату буенча РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктының 6 пунктчасында каралган аукцион яки арендага алуга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү турында гариза кергән;<br>13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата РФ Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, дача хуҗалыгы яки крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеге өчен җир участогы бирү турында хәбәр басылып чыккан һәм урнаштырылган;<br>14) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану, территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә линия объектын | |

| | | |
|---|---|---|
| | урнаштыру очракларыннан тыш, җир участогын бирү турындагы гаризада күрсәтелгән мондый җир участогыннан файдалану максатларына туры килми;<br>15) сорала торган җир участогы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган оборона һәм куркынычсызлык ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм күрсәтелгән ихтыяҗлар өчен вакытлыча кулланылмый торган җир участоклары исемлегенә кертелмәгән, әгәр җир участогы бирү турында гариза РФ Җир Кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән булса;<br>16) яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән чик күләмнән артып китә;<br>17) җир участогы бирү турында гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге объектлар төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>18) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъектының дәүләт программасы нигезендә бина, корылмалар урнаштыру өчен билгеләнгән һәм җир участогы бирү турында гариза белән әлеге биналар, корылмаларны төзүгә вәкаләтле булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>19) күрсәтелгән хокуклар буенча җир участогы бирү рөхсәт ителми;<br>20) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 21) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәгән;<br>22) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аның гамәлдә булу срогы чыкмаган һәм җир участогы бирү турындагы гариза белән бу карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать иткән;<br>23) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алынган һәм гаризада күрсәтелгән җир участогын бирү максаты мондый җир участогын тартып алу максатларына туры килми, мондый җир участогында урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир участокларыннан тыш;<br>24) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль закон нигезендә аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләре төгәлләштерелергә тиеш;<br>25) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы җир участогын урнаштыру схемасында, территорияне межалау проектында яки урман участокларының урнашу урыны, чикләре, мәйданы турында һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турында проект документларында (алар нигезендә ун проценттан артык күләмдә шундый җир участогы барлыкка китерелгән) күрсәтелгән мәйданнан артып китә; | |
| 2.10. Дәүләт пошлинасы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Гариза кәгазьдә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә бирелә.<br>Бина гариза тутыру өчен өстәл һәм урындыклар, гаризаны тутыру үрнәкләре һәм хезмәттән файдалану өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, мәгълүмат ресурсларында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http:// www.nabchelny.ru.), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафынна «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль берәмлеге сайтында (http:// www.nabchelny.ru.), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮдә алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон формада файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки Бердәм  дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. 3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) шартнамә төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Башкарма комитетка шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә документлар тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада электрон почта яисә Интернет-кабул итү бүлмәсе аша Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Башкарма комитет эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече, гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең шәхесен билгелүне;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);

3) әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерүне;

4) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килешенмәгән башка төзәтүләр булмау) тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризаны кабул итүне һәм махсус журналда теркәүне;

2) гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билгеләп, гариза һәм тапшырылган документлар исемлегенең күчермәсен тапшыруны;

3) гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Башкарма комитет эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза теркәлгән көнне, теркәлгән документлар белән гаризаны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына тапшыра.

3.3.4. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИ башлыгына җибәрә.

3.3.3. һәм 3.3.4 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгына (алга таба – ҖММИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм хәбәрне, индивидуаль торак төзелеше өчен җир участогы бирү мөмкинлеге турында һәм хәбәр бастырып чыгарылган һәм урнаштырылган көннән башлап утыз көн эчендә, мондый җир участогын бирү белән кызыксынган гражданнарның мондый җир участогын сату буенча аукционда яки мондый җир участогын

арендалау тшартнамәсе төзү хокукына аукционда катнашырга нияте булу турында гариза бирү хокукы турында мәгълүматны күрсәтеп, вакытлы матбугат басмасында («Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газетасы) һәм «Интернет» челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (http:/ www.nabchelny.ru) бастырып чыгару өчен ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгеченә (алга таба - ҖММИ бүлеге белгече) җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: хәбәрне бастырып чыгару һәм алга таба эшләү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. һәм 3.3.6 пунктлар белән билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыру срогы – 2 көн.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнаргаҗибәрү

3.4.1. ҖММИ бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаны һәм документларны карап тикшерүне;

2) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрослар формалаштыруны һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада җибәрүне.

Срок - 2 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон төрдә җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрә (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар ведомствоара запрос документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавапны әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүматлар) яисә ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазьләре.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. ҖММИ бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек буенча алынган документлар (мәгълүматлар) (һәм аукцион нәтиҗәләре, соңгысы үткәрелгәндә) нигезендә :

1) хәбәр басылып чыккан көннән 30 көн эчендә башка гражданнардан җир участогы бирү турында гаризалар (җир участогы формалаштырылган һәм кадастр исәбенә куелган очракта) яки кире кагу турында хат (җир участогын формалаштырырга һәм кадастр исәбенә куярга кирәк булса) кермәгән булса, җир

участогын сату-алу (арендалау) шартнамәсе проектын (алга таба - шартнамә) әзерләүне гамәлгә ашыра,

2) шартнамә проектын килештерү өчен яки баш тарту турындагы хатны имзалау өчен ҖММИ башлыгынаҗибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына җибәрелгән килештерү өчен шартнамә проекты яки имзалау өчен баш тарту турында шартнамә.

Процедураны гамәлгә ашыру срогы – 3 көн.

3.5.2. ҖММИ башлыгы шартнамә проектын килештерә һәм аны килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә яки баш тарту турында хатны имзалый һәм теркәү өчен Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты яисә имзаланган һәм теркәү өчен Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгеченә җибәрелгән хат.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамлаган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.3. Хокук идарәсе шартнамә проектын карап тикшерә һәм килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм, әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен, аны ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Процедураны гамәлгә ашыру срогы – 2 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән шартнамә проекты яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.5.4. Хокук идарәсе тарафыннан шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм шартнамә проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты.

Процедураны гамәлгә ашыру срогы – 2 көн.

3.5.5. Хокук идарәсе төзәтелгән шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән шартнамә проекты.

Процедураны гамәлгә ашыру срогы – 2 көн.

3.5.6. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары шартнамә проектын имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзаланган, теркәү һәм гариза бирүчегә бирү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.6. Шартнамә төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы хатны терки;

2) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хатны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында ханы гариза бирүчегә имза куйдырып бирә яисә почта аша җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат .

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат имзаланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. ҖММИ бүлеге белгече:

1) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, муниципаль хезмәт нәтиьәсен бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә;

2) шартнамәне теркәү журналында терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан шартнамә имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итү һәм шартнамәне теркәү.

3.6.3. ҖММИ бүлеге белгече, шартнамәнең өч нөсхәсен имзалау өчен, имза куйдырып гариза бирүчегә (аның вәкиленә) бирә яисә почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гамәлгә ашырыла:

1) гариза бирүче шәхсән килгән очракта – 15 минут эчендә;

2) шартнамә почта аша җибәрелгән очракта – әлеге Регламентның 3.6.2 пунктчасында каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап өч көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яисә почта аша җибәрелгән шартнамә.

3.6.4. Гариза бирүче шартнамәне өч нөсхәдә имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә тапшыра.

Әлеге процедураның срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче тарафыннан имзаланган һәм ҖММИ бүлеге белгеченә тапшырылган шартнамә.

3.7. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү, КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган шартнамәдә техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә өч нөсхәдә бирелгән техник хаталы шартнамә;

2) техник хата булуны дәлилли торган юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган шартнамәдә күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.8.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм аларны ҖММИга тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен ҖММИ белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.3. ҖММИ белгече документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган шартнамәгә төзәтмәләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән шартнамәне гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки, техник хаталы документның төп нөсхәсен ҖММИгә биргән очракта, документны алу мөмкинлеге турында гариза бирүченең адресы буенча почта аша (электрон почта аша) хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) шартнамә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү, Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча карар проектларын тикшерү һәм килештерү; Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш башкаруны алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитетның агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы була.

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы була.

Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләре муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада Башкарма комитетка яки Башкарма комитет Җитәкчесенә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.tatar.ru), Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта

яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе (аны алмаштыручы зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка рәвештә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта Башкарма комитет Җитәкчесе кимчелекләрне бетерү максатларында күрелергә тиешле чараларны билгели. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясенең гражданлык һәм арбитраж процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә судта шикаять бирелергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

1 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесе

__________________________________________

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

__________________________________________

__________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Индивидуаль торак төзелеше өчен
җир участогын милеккә (арендага) бирү турында
гариза

Сездән индивидуаль торак төзелеше өчен җир участогын милеккә (арендага) бирүне сорыйм.

Мәйданы ____________ кв.м, кадастр номеры _______________:_________, рөхсәт ителгән файдалану төре ____________________________ булган, __________________ җирләр категориясеннән __________________ муниципаль район (шәһәр округы), ___________________________ торак пункты ______________ урамы ________ йорт адресы буенча урнашкан җир участогы.

Гаризага түбәндәге документлар (сканкопияләр) теркәлә:

1) Шәхесне раслаучы документ күчермәсе;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) Территорияләрнең кадастр планында җир участогын урнаштыруның расланган схемасы (әгәр җир участогын барлыкка китерергә туры килсә һәм чикләрендә җир участогы барлыкка китерү каралган территорияне межалау проекты расланмаган булса).

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул иосәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән


мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушымта итеп бирелгән документлар (документлар сканкопияләре) гариза бирелгән вакытка Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, бу документлар дөрес һәм дөрес белешмәләрдә була.


Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | ___________________ | ( _________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

2 нче кушымта

# Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




ҖММИ бүлеге белгече алынган документлар (мәгълүматлар) нигезендә: Шартнамә проектын яки баш тарту турында хат әзерләүне гамәлгә ашыра; ҖММИ башлыгына килештерү өчен шартнамә проектын яки имзалау өчен баш тарту турында хатны җибәрә
Шартнамә проекты яки баш тарту турында хат
ҖММИ башлыгы: шартнамә проектын килештерә яки баш тарту турында хатны имзалый; шартнамә проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә яки баш тарту турында имзаланган хатны теркәү өчен Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Имзаланган баш тарту турында хат
Килештерелгән шартнамә проекты
Хокук идарәсе шартнамә проектын килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә яки шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Килештерелгән шартнамә проекты
ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм шартнамә проектын килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары шартнамә проектын имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Имзаланган шартнамә проекты
ҖММИ бүлеге белгече әлеге регламентның 3.6.2 пунктында билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра
Теркәлгән шартнамә
ҖММИ бүлеге белгече шартнамәнең өч нөсхәсен имзалау өчен гариза бирүчегә бирә яисә почта аша җибәрә
Гариза бирүчегә бирелгән яисә почта аша җибәрелгән шартнамә
Гариза бирүче өч нөсхәдә шартнамәне имзалый һәм ҖММИ бүлеге белгеченә тапшыра
Имзаланган шартнамә
Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече әлеге регламентның 3.6.1 пунктында билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра
Гариза бирүчегә бирелгән баш тарту турында хат

3 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесе

___________________________________

Кемнән _______________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________________________________

(хезмәтнең исеме)

Язылган ______________________________________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ______________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail адресы: ___________ җибәрү юлы белән;

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша түбәдәге адрес буенча: _____________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә; гариза бирелгән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ ___________________ ( __________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-07 | |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 30-55-42 | |
| Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы | 30-55-54 | |
| ҖММИ белгечләре | 30-59-12<br>30-57-11<br>30-57-05 | |